| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **с. Тюлячи** **БОЕРЫК**

**«02» февраль 2021** **№ 10**

Муниципаль учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүгә план күрсәткечләрен формалаштыру турында

«Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан 2021 елга түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәрен һәм максатчан сарыф ителергә тиешле керемнәрдән тыш, күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 11 декабрендәге 1130 номерлы карары нигезендә,

1. «2021 елга Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керем күләмнәренең планлы күрсәткечләрен һәм максатчан сарыф ителергә тиешле керемнәрдән тыш, күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 11 декабрендәге 1130 номерлы карары белән расланган, Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, 2021 елга муниципаль учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүгә планлы күрсәткечләр төзегәндә, муниципаль учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керем күләмнәренең һәм күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган план күрсәткечләрен, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, 3 номерлы кушымта нигезендә исәпкә алырга.

2. Әлеге күрсәтмәнең 1 пунктын гамәлгә ашыру буенча җаваплы орган итеп Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасын билгеләргә.

3. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары - территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге бүлеге башлыгы И.Ә. Миңнегуловка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин